Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР №1**

Шумково авылы 2023 нче елның 9 нчы гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 13 нче октябрендәге «Җир салымы турында»гы 11 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодыксының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 02.07.2021 ел, 305-ФЗ Федераль закон, техник хатаны бетерү һәм муниципаль норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең 2014 нче елның 13 нче октябрендәге «Җир салымы турында»гы 11 нче номерлы карарын исәпкә алып, Балык Бистәсе муниципаль районының «Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 13 нче октябрендәге 11 нче номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында «, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәкләрен куллану» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2020 нче елның 10 нче февралендәге «Җир салымы турында»гы 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2021 нче елның 29 нчы декабрендәге 10 нче номерлы карарын юкка чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 нче елның салым чорына җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково авылы, Үзәк урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Атмас авылы, Центральная ур., 42 нче йорт; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы, Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 нче йорт; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Әшнәк-Качкалак авылы, Югары урамы, 5 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интренет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru шулай ук «Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шумково авыл җирлеге башлыгы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Татарстан Республикасы Л.М. Нәҗмиев